ШИМБӘ
20 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 91 (5891)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

Физкультурага—киң юл

Физкультура-спорт хәрәкәте—безнең илдә ул коммунистик тәрбиянең аерылмас бер өлеше, культура төзелеше фронтының иң әһәмиятле тармакларыннан берсе. Физкультура-спорт яңа кешене тәрбияләп үстерүгә һәм чыныктыруга ярдәм итә. Физкультура белән чыныккан унар меңнәрчә яш патриотлар хезмәттә иң югары күрсәткечләрне бирүгә, илне саклауда зур батырлыклар һәм каһәрманлыклар күрсәтүгә хәзер торалар һәм күрсәтәләр.

Партиянең һәм хөкүмәтнең көндәлек игтибары нәтиҗәсендә безнең илдә физкультура хәрәкәте гаять зур колач алды. Спортның һәр төре зур популярлек белән файдалана. Совет спортчылары елдан-ел бөтен дөнья рекордларын яулап алалар. Футбол, бокс, җиңел атлетика һәм башка төрләр буенча үткәрелә торган ярышларны миллионнар карыйлар һәм сагынып көтеп алалар.

Казанда да физкультура-спорт эшендә күзгә күренерлек уңышлар бар. Узган ел Казан физкультурниклары тугыз республика спартакиадасында беренче урынны алуга ирештеләр. Казанның „Динамо“, „Спартак“ һәм башка кайбер спорт җәмгыятьләрендә эш ярыйсы гына куелган. Ләкин, Казандагы күп санлы предприятиеләрне, уку йортларын алып караганда бик күп җитешсезлекләргә очрарга туры килә.

Татарстанның бик күп районнарында физкультура хәрәкәтенә җитәкчелек гаять начар тора. Физкультура-спорт комитетының районнардагы уполномоченныйлары,—Чистай, Бөгелмә, Тәтеш, Алабуга, Арча, Чаллы, Минзәлә һәм башка кайбер районнарны исәпкә алмаганда,—искиткеч дәрәҗәдә эшлексезлек, гамсезлек күрсәтәләр. Мамадыш райуполномоченныеның эше көн саен диярлек канцеляриедә кәгаз актарынып утырудан, яки очраганда бер допризывниклар янына барып кайтудан ерак китми. Саба районында да хәл шундый ук.

Моның сәбәбе, әлбәттә, район оешмаларының бу эш белән тиешенчә кызыксынмауларында. Район уполномоченныйларының эшенә контроль алып барылмый. Райсоветларның башкарма комитетлары аларны үз язмышларына тапшыралар. Республиканың Физкультура-Спорт Комитеты да үзенең бурычын бик еш вакытларда уполномоченныйларга кәгазьләр, сораулар язып җибәрүгә генә кайтарып калдыра. Урыннар белән җанлы элемтә, аларга чын большевистик җитәкчелек юк. Ә күп урыннарда райсоветларның башкарма комитетларыннан алып түбәнге оешмаларга кадәр физкультура хәрәкәтенә тиешле әһәмият бирмиләр.

Яз көннәре башланды. Тиздән профсоюзларның Шверник исемендәге язгы массовый кроссы булачак. Бу кросс быел ГТО ның яңа комплексы дистанцияләренә үткәреләчәк. Димәк ул, ГТО значокларына массовый рәвештә нормалар тапшыруда иң әһәмиятле чара булып тора. Татарстан районнарындагы кросслар турында сөйләп тә тормастан, Казанда моңа кадәр булган кросслар уңае белән әйтергә кирәк: алар хәзерлексез үткәреләләр. Катнашучылар саны аз була. Кросс алдына куелган төп бурыч үтәлми кала. Күрсәткечләр канәгатьләнерлек булмый. ГТО буенча чаңгы нормаларының быел начар үтәлүе, чаңгы кроссларының канәгатьләнерлек рәвештә оештырылмаулары моны бик ачык күрсәтеп тора. Быелгы язгы кросска да хәзерлек әле Казанның 1—2 спорт җәмгыятендә генә башланган.

Язгы-җәйге спортны башлап җибәрү бәйрәме булган кроссларда меңнәрчә һәм унар меңнәрчә яшьләрнең ГТО га норма тапшыруларына ирешергә кирәк. Шуның өчен, кроссларга иң ныклы һәм үрнәк хәзерлекне тәэмин итәргә кирәк. Физкультурниклар массасын ныклап хәзерләми торып, ныклы тренировка үткәрми торып, кроссның уңышлы үтүенә, ГТО нормаларының масса күләмендә тапшырылуына ирешеп булмаячак.

Язгы-җәйге сезонны һәр яктан хәзер хәлдә каршылау—физкультура-спорт оешмаларының зур җаваплы бурычы. Масса-өйрәнү эшенең ныклы графиклары һәм нормалар тапшыруның сроклары нык рәвештә билгеләнгән булырга тиеш.

Спорт язын, спорт җәен тулы хәзерлек белән каршыларга кирәк. Моның өчен бөтен спорт корылмалары, инвентарьлар, җиһазлар сугышчан хәзерлек хәленә китерелергә тиеш. Ныклы план төзеп эшкә керешү, ярышларның реаль календарын билгеләү, спортның оборона төрләрен җәелдерүгә һәм, бигрәк тә спорт җәмгыятьләренә яңа членнар туплауга, физкультурниклар сафларына яңа көчләр туплауга, аерым алганда хатын-кыз яшьләрне регуляр физкультура занятиеләренә тагын да кинрәк тартуга бөтен көчне бирү—менә, физкультура-спорт оешмаларының бүгенге бурычларының әһәмиятле өлеше шуннан гыйбарәт.

Шушы таләпләр нигезендә, спорт чаралары календарының яңа физкультурниклар өчен дә, квалификацияле физкультурниклар өчен дә, караучылар өчен дә кызыклы булуына ирешергә кирәк.

Алда торган язгы-җәйге спорт сезоны орденлы Татарстанга унар меңнәрчә яңа значкистлар, квалификацияле меңнәрчә спортчылар, уннарча рекордчылар бирергә тиеш.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ
СССР Электр Промышленносте Халык Комиссариаты төзү турында

1. Гомуми союз Электр Промышленносте Халык Комиссариаты төзергә, аның составына казан-турбина төзелеше заводларын һәм түбәндәге предприятиеләрне кертергә: электр машиналары төзелеше, электр аппаратлары төзелеше, телефон-телеграф, аккумулятор, кабель, вакуумлы техника, электр изоляциясе, электр үлчәү приборлары, автоматика, теле-механика приборлары, радио аппаратлары предприятиеләре.

2. Предприятиеләрне һәм оешмаларны СССР Электр Промышленносте Халык Комиссариатына расланган исемлек буенча тапшырырга.

3. Авиация Промышленносте Халык Комиссариатының, Суднолар Төзелеше Халык Комиссариатының һәм Элемтә Халык Комиссариатының СССР Электр Промышленносте Халык Комиссариатына күчә торган предприятиеләренә һәм төзелешләренә хезмәт күрсәтүче Баш Идарәләрен СССР Электр Промышленносте Халык Комиссариаты карамагына тапшырырга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 17 апрель, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ
СССР Электр Станцияләре һәм Электр Промышленносте Халык Комиссариатын СССР Электр Станцияләре Халык Комиссариаты итеп үзгәртеп кору турында

1. СССР Электр Промышленносте Халык Комиссариаты төзелү уңае белән СССР Электр Станцияләре һәм Электр Промышленносте Халык Комиссариатын СССР Электр Станцияләре Халык Комиссариаты итеп үзгәртеп корырга, район җылылык-электр станцияләрен, гидро-электростанцияләрен, электр челтәрләрен, җылылык челтәрләрен һәм район электр станцияләре төзелешен аның карамагында калдырырга.

2. Район электр станцияләренә хезмәт күрсәтүче торф предприятиеләрен һәм оешмаларын РСФСР Җирле Ягулык Промышленносте Халык Комиссариаты карамагыннан СССР Электр Станцияләре Халык Комиссариаты карамагына тапшырырга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 17 апрель, 1940 ел.

ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫНДА

ССР СОЮЗЫ СОВНАРКОМЫ ЯНЫНДАГЫ ЭКОНОМСОВЕТНЫҢ ЭШЕН ҮЗГӘРТЕП КОРУ ТУРЫНДА

ССР Союзы Совнаркомы „ССР Союзы Совнаркомы янындагы Экономсоветның эшен үзгәртеп кору турында“ карар кабул итте.

Наркоматларны ваклау, наркоматларның саны арту, СССР Совнаркомы янында яңа Комитетлар һәм Идарәләр төзелү, промышленностьның һәм авыл хуҗалыгының барлык тармакларының тагын да үсүе җитәкчелек итү бурычларын, бигрәк тә СССР Совнаркомы янындагы хуҗалык наркоматларына һәм учреждениеләренә җитәкчелек итү бурычларын катлауландырдылар һәм күп санлы хуҗалык наркоматларының эшләрен бергә бәйләү һәм берләштерү турындагы актуаль мәсьәләне куйдылар.

Хәзерге хәлдә, Совнарком һәм, бигрәк тә Экономсовет күп мәсьәләләрне карарга һәм күп санлы наркоматлар, үзәк учреждениеләр һәм җирле органнар белән көн саен эш итәргә тиеш булганда,—Совнарком һәм Экономсовет хуҗалык наркоматларындагы чын хәлне конкрет төстә белә алмыйлар, аларның ихтиаҗларын һәм аларда булган файдаланылмаган мөмкинлекләрне вактында белә алмыйлар, шулай ук Совнарком һәм Экономсовет карарларын аларның үтәүләрен тикшерә алмыйлар, шуның нәтиҗәсендә бездә әле чын хуҗалык планы һәм аны үтәүне тиешенчә тәэмин итү юк. Шуның өстенә Совнарком Председателенең урынбасарлары, бер үк вакытта наркоматларда да эшләгәнлектән, хуҗалыкның аерым тармакларына җитәкчелек итүгә туплана алмыйлар.

Хуҗалык наркоматларына җитәкчелек итү буенча Совнаркомның һәм Экономсоветның эшен яхшырту һәм Экономсоветка хуҗалык тармаклары арасында тиешле элемтә булдыруны тәэмин итү, халык хуҗалыгын планлаштыру эшен һәм билгеләнгән планнарны үтәү эшен яхшырту теләге белән ССР Союзы Совнаркомы карар бирде:

1. ССР Союзы Совнаркомы янында түбәндәге хуҗалык советлары төзергә:

а) Металлургия һәм Химия Советы;
б) Машина Төзелеше Советы;
в) Оборона Промышленносте Советы;
г) Ягулык һәм Электр Хуҗалыгы Советы;
д) Киң Куллану Товарлары Советы;
е) Авыл Хуҗалыгы һәм Хәзерләүләр Советы;

2. ССР Союзы Совнаркомы янындагы хуҗалык Советларына түбәндәге наркоматларның һәм ССР Союзы Совнаркомы янындагы Баш Идарәләрнең эшләренә җитәкчелек итү функцияләрен йөкләргә:

а) Металлургия һәм Химия Советына:
Кара металлургия наркоматы,
Төсле металлургия наркоматы,
Химия промышленносте наркоматы.

ССР Союзы Совнаркомы янындагы Сульфит—Спирт һәм Гидролиз Промышленносте Баш Идарәсе эшенә җитәкчелек итүне йөкләргә;

б) Машина Төзелеше Советына:
Авыр Машина Төзелеше наркоматы,
Уртача Машина Төзелеше наркоматы,
Гомуми Машина Төзелеше наркоматы,
Электр Промышленносте наркоматы эшенә җитәкчелек итүне йөкләргә;

в) Оборона Промышленносте Советына:
Авиация Промышленносте наркоматы,
Кораллар наркоматы,
Сугыш кирәк-яраклары наркоматы,
Суднолар Төзелеше наркоматы эшенә җитәкчелек итүне йөкләргә;

г) Ягулык һәм Электр Хуҗалыгы Советына:
Күмер Промышленносте наркоматы,
Нефть Промышленносте наркоматы;
Республикаларның Ягулык Промышленносте наркоматлары (Союзный республикаларның совнаркомнары аркылы),
Электр станцияләре наркоматы эшенә җитәкчелек итүне йөкләргә;

д) Киң Куллану Товарлары Советына:
СССР Текстиль Промышленносте наркоматы,
СССР Җиңел Промышленносте наркоматы,
СССР Азык Промышленносте наркоматы,
СССР Ит һәм Сөт Промышленносте наркоматы,
СССР Балык Промышленносте наркоматы эшенә җитәкчелек итүне йөкләргә;

е) Авыл Хуҗалыгы һәм Хәзерләүләр Советына:
СССР Җир Эшләре наркоматы,
СССР Совхозлар наркоматы,
Хәзерләүләр наркоматы эшенә җитәкчелек итүне йөкләргә.

3. ССР Союзы Совнаркомы янындагы 1 нче пунктта күрсәтелгән хуҗалык советларының председательләре ССР Союзы Совнаркомы Председателенең урынбасарлары булырга тиешләр. Алар ССР Союзы Совнаркомы янындагы Экономсовет составына керәләр.

4. Хуҗалык Советларының составы өч кешедән 5 кешегә кадәр булган санда аерым рәвештә ССР Союзы Совнаркомы тарафыннан раслана. Совет членнары өчен бер үк вакытта бары тик ССР Союзы Совнаркомы янындагы Госпланда гына эшләүгә юл куела.

5. ССР Союзы Совнаркомы янындагы Хуҗалык Советларының функцияләре оператив характерда була. Советлар үз карамакларындагы наркоматларга бойрыклар бирәләр һәм бу бойрыклар шушы наркоматлар өчен мәҗбүри була.

6. Хуҗалык Советлары мәсьәләләрне хәзерләү һәм үтәлүне тикшерү эшләрендә ССР Союзы Совнаркомы янындагы Госпланга һәм Совет Контроле Комиссиясенә таяналар.

7. ССР Союзы Совнаркомы янындагы Хуҗалык Советлары ССР Союзы Совнаркомы янындагы Советларның карарларын хәзерләү һәм үтәлешне тикшерү буенча үзләре янында секретариатлар төзиләр.

ССР Союзы Совнаркомы янындагы Металлургия һәм Химия Советының Председателе итеп иптәш **Н. А. Булганин** билгеләнде. Шул уңай белән ул ССР Союзы Верховный Советы Президиумының Указы белән ССР Союзы Дәүләт Банкысы Правлениесе Председателе хезмәтләреннән азат ителде;

ССР Союзы Совнаркомы янындагы Машина Төзелеше Советының Председателе итеп иптәш **В. А. Малышев** билгеләнде. Шул уңай белән ул ССР Союзы Верховный Советы Президиумының Указы белән ССР Союзының Авыр Машина Төзелеше Халык Комиссары хезмәтләреннән азат ителде;

ССР Союзы Совнаркомы янындагы Оборона Промышленносте Советының Председателе итеп иптәш **Н. А. Вознесенский** билгеләнде. Шул ук вакытта ул ССР Союзы Совнаркомы янындагы Госплан Председателе хезмәтендә дә калдырылды;

ССР Союзы Совнаркомы янындагы Ягулык һәм Электр Хуҗалыгы Советының Председателе итеп иптәш **М. Г. Первухин** билгеләнде. Шул уңай белән ул СССР Верховный Советы Президиумының Указы белән ССР Союзының Электр Станцияләре һәм Электр Промышленносте Халык Комиссары хезмәтләреннән азат ителде;

ССР Союзы Совнаркомы янындагы Киң Куллану Товарлары Советының Председателе итеп иптәш **А. Н. Косыгин** билгеләнде. Шул уңай белән ул СССР Верховный Советы Президиумының Указы белән ССР Союзының Текстиль Промышленносте Халык Комиссары хезмәтләреннән азат ителде. (ТАСС).

ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ ТУЛУ КӨНЕ АЛДЫННАН

Ленин булган урыннарга хезмәт ияләренең массовый экскурсияләре

В. И. Лениннең туувына 70 ел тулу уңае белән ВЦСПС ның туризм-экскурсияләр идарәсенең җирле органнары Владимир Ильичнең тормышы һәм революцион эше белән бәйләнгән урыннарга хезмәт ияләренең массовый экскурсияләрен оештыралар.

Ленинградта „Ленин һәм Сталин—Октябрь Социалистик революциясенең юлбашчылары“ дигән темадагы экскурсияләр зур популярлек белән файдаланалар. Бу экскурсиянең маршруты Ленин чит илдән кайтканнан соң 1917 нче елда беренче тапкыр буларак речь сөйләгән Финляндия вокзалы мәйданыннан башлана. Аннары экскурсиягә катнашучылар элекке Кшесинская сарае, „Модерна“ циркы районына юнәләләр, Карл Маркс проспектында РСДРП ның VI нчы съезды ачылган йортны, Смольныйны, Владимир Ильич торган йортларны карыйлар. Экскурсия Урицкий мәйданында тәмам була. Монда Кышкы сарайга штурм ясау һәм аны алу картинасы күз алдына килеп баса.

Казанда Лениннең күп истәлекләре сакланган. Шәһәрнең хезмәт ияләре һәм читтән килүчеләр өчен Ленин укыган университетка, Ульяновлар семьясе яшәгән һәм хәзер музейгә әйләндерелгән йортка экскурсияләр ясала.

Куйбышевта элекке окружной суд бинасын карау өчен экскурсия оештырыла. Моннан күп еллар элек Владимир Ильич бу йортта булгалаган.

Җәй көне туристлар һәм экскурсантлар В. И. Лениннең һәм Н. К. Крупскаяның Красноярски краенда сөргендә вакыттагы тормышлары белән таныша алалар. Бу маршрут Шушенское авылы аркылы үтә. Хәзерге вакытта анда В. И. Ленин музей-йорты ачылды. Шушенское авылына якын урында Ильичнең ауга йөрергә яраткан күле бар.

Москвадагы туризм-экскурсияләр идарәсе В. И. Лениннең тормышы һәм революцион эше белән бәйләнгән урыннарга башкалада хезмәт ияләренең массовый экскурсиясен оештыра. Экскурсиягә катнашучылар Куйбышевта, Ульяновскида һәм Казанда булачаклар. Экскурсантлар маршрутның бер өлешен пароходта үтәчәкләр. (ТАСС).

В. И. ЛЕНИННЕҢ БИОГРАФИЯСЕ

Владимир Ильич Лениннең туувына 70 ел тулу көненә политик әдәбият дәүләт издательствосы Ем. Ярославскийның „В. И. Лениннең биографиясе“ дигән китабын басып чыгарды. Бу китап Владимир Ильич Лениннең тормышы, аның революцион эше һәм Лениннең Сталин белән бөек идея дуслыгы турында популяр формада сөйли.

Элекке басмасы белән чагыштырганда, бу китап „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“на туры китерел, яңа баштан эшләнгән. Аңар: „Сталин—ул бүгенге Ленин“ һәм „Ленин һәм Сталин“ дигән яңа ике бүлек кертелгән.

Укучылар Ленин турында декламацияләр өйрәнәләр

Сталин районының 2 нче номерлы урта мәктәбе Ленинне искә алу кичәсенә махсус номерлар хәзерли. 3 нче „А“ классы укучылары Ленингә багышлап язылган „Өч иптәш“ дигән декламацияне өйрәнәләр. Шулай ук Владимир Ильич Ленингә багышланган башка җыр, декламацияләр дә өйрәнелә. Хәзер отрядларда һәм классларда беседалар алып барыла.

21 нче апрельдә мәктәп күләмендә Ильичне искә алуга багышланган кичә үткәрелә. Югары класс укучыларының Кокушкино (хәзерге Ленино) авылына походларын үткәрергә уйланыла.

***

„Спартак“ комбинатының фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбе Владимир Ильич Лениннең туувына 70 ел тулу көненә хәзерләнә. Хәзер классларда В. И. Ленин турында беседалар алып барыла. 22 нче апрельдә укучыларның һәм укытучыларның Ильичне искә алуга багышланган тантаналы җыелышы үткәрелә. Җыелышта мәктәп директоры иптәш Строганов Лениннең тормышы һәм революцион эше турында доклад ясаячак.

Партиянең Казан Шәһәр активы җыелышы

Кичә кич сәгать 6 да, Менжинский исемендәге клубта партиянең Казан Шәһәр активы җыелышы башланды.

Җыелышның почетлы президиумын сайлау турындагы тәкъдим бик зур күтәренкелек белән каршы алынды. Озакка сузылган көчле алкышлар астында почетлы президиумга ВКП(б) Үзәк Комитеты политбюросы сайланды.

ВКП(б) Үзәк Комитетының март пленумы йомгаклары турында зур доклад белән ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш А. Н. Алемасов чыкты. Актив җыелышы докладны гаять зур игтибар белән тыңлады. Иптәш Алемасов үзенең докладында ВКП(б) Үзәк Комитеты пленумы тарафыннан кабул ителгән карарларның эчтәлегенә тулы рәвештә тукталды. Докладтан соң фикер алышулар башланды. Чыгып сөйләүчеләр ВКП(б) Үзәк Комитетының март пленумы карарларын бердәм рәвештә яхшы дип табуларын әйттеләр.

Җыелыш бүген кичке 6 дан, шул ук бинада үзенең эшен дәвам иттерәчәк.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ
Ленинград предприятиеләрен һәм учреждениеләрен бүләкләү турында

Илебезнең оборона сәләтен ныгыту буенча хөкүмәт заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен бүләкләргә:

Ленин ордены белән

1. Суднолар төзелеше промышленносте наркоматының Ижорский заводын.
2. Суднолар төзелеше промышленносте наркоматының Серго Орджоникидзе исемендәге 189 нчы номерлы заводын.
3. Сугыш кирәк-яраклары наркоматының элек Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән 5 нче номерлы заводын.

Кызыл Байрак ордены белән

Элек Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән Киров заводын.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән

1. Авиация промышленносте наркоматының 210 нчы номерлы заводын.
2. Уртача машина төзелеше наркоматының 174 нче номерлы заводын.
3. Җиңел промышленность наркоматының Володарский исемендәге тегү фабрикасын.
4. Ленинградның кан күчерү буенча Фәнни-практик институтын.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 17 апрель, 1940 ел.

ЛЕНИНГРАД ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕ ҺӘМ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ РАБОТНИКЛАРЫН БҮЛӘКЛӘҮ

Илебезнең оборона сәләтен ныгыту буенча уңышлы эшләре өчен һәм күрсәткән инициативалары өчен СССР Верховный Советы Президиумы Ленинград предприятиеләренең һәм учреждениеләренең 1.280 работнигын СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләде.

Ленин ордены белән 23 кеше, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән 107 кеше, Кызыл Йолдыз ордены белән 67 кеше, „Почет билгесе“ ордены белән 304 кеше, „Сугышчан хезмәтләр күрсәткән өчен“ медале белән 21 кеше, „Хезмәттәге батырлык өчен“ медале белән 345 кеше һәм „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән 413 кеше бүләкләнде.

ХРОНИКА

СССР Верховный Советы Президиумының указлары белән:

— Иптәш Алексей Николаевич Косыгин, СССР текстиль промышленносте халык комиссары хезмәтләреннән азат ителеп, СССР Халык Комиссарлары Советы Председателенең урынбасары итеп билгеләнде.

— СССР Халык Комиссарлары Советы председателе урынбасары иптәш Николай Александрович Булганин СССР Дәүләт банкысы правлениесенең председателе хезмәтләреннән азат ителде.

— Иптәш Николай Константинович Соколов СССР Дәүләт банкысы правлениесенең председателе итеп билгеләнде.

— Иптәш Александр Илларионович Ефремов СССР авыр машина төзелеше халык комиссары итеп билгеләнде.

— Иптәш Илья Николаевич Акимов СССР текстиль промышленносте халык комиссары итеп билгеләнде.

— Иптәш Василий Васильевич Богатырев СССР электр промышленносте халык комиссары итеп билгеләнде.

— Иптәш Андрей Иванович Летков СССР электр станцияләре халык комиссары итеп билгеләнде.

ТАТАРСТАН БАСУЛАРЫНДА

Лаеш районының „Красный дол“ колхозында даими звеноларга беркету өчен участокларны үлчәү вакты. Сулдан уңга—бригадир А. Трифонов, звено башлыкларыннан А. Сычев һәм М. Медведьев иптәшләр. С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Кыр эшләре масса күләмендә башланды

ТӘКӘНЕШ, 19 апрель. (Телефон буенча). Районлагы 86 колхоздан 58 колхоз тырмалау, культивацияләү һәм язгы сөрү эшләренә керештеләр. Тукай һәм Маркс исемендәге колхозлар кичә арпа һәм солы чәчтеләр. „Коммунар“ колхозы (председателе иптәш Кузнецов) 48 гектар бодай чәчте. Бу колхозда кыр эшләре оешкан рәвештә бара. Эшнең сыйфаты яхшы.

Шуның белән бергә, кайбер колхозларда эшнең сыйфатына игътибар бирмәү фактлары бар. Мәсәлән, Ворошилов исемендәге колхозда (председателе иптәш Хафизов) тугга сөрелгән җирне ачык-моннан гына тырмалап чәчкәннәр. Бу колхозда даими звенолар тәртибендә эшләү юк. Бу җитешсезлекләр иптәш Әхмәдиев бригадасында аеруча ачык сизелә.

Шәйхеттинев.

ЭШ УҢЫШЛЫ БАРА

Мәслим районында язгы кыр эшләре зур күтәренкелек белән башланды. „Лена“ колхозында эш аеруча яхшы бара. Бу колхозда 16 нчы апрельдә культивацияләү көнлек норма 157 процентка, тырмалау буенча 138 процентка, чәчү буенча 113 процентка үтәлде.

Беренче бригаданың тырмачысы, Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә кандидат Вәли иптәш Шәйдуллин 5 гектар урынына 11 гектар тырмалады, комсомол комитеты секретаре Нәҗип иптәш Сабиров 12 гектар тырмалады. Культивацияләүчеләрдән Насыйров һәм Гыйлфанов иптәшләр 4 гектар урынына 8,5 гектар культивацияләделәр. Чәчүчеләрдән Гыйлфанов, Садыйков иптәшләр нормаларны 160 процент итеп үтиләр.

Колхозда масса-аңлату эшләре яхшы оештырылган. Агитаторлар кырга чыгып, газеталар укыйлар, беседалар үткәрәләр. Бригадаларда, звеноларда стена газеталары системалы рәвештә чыгарыла. Анда алдынгылар һәм эш тәҗрибәләре һәм нормаларны үтәүләре яктыртыла.

„Биектау“, „Кызыл Тәбәк“, „Корыч кул“ һәм „Туры Юл“ колхозларында да язгы кыр эшләре уңышлы бара. Колхозлар чәчүне кыска срокларда, яхшы сыйфатлы итеп тәгәлләү өчен көрәшәләр. (ТатТАСС).

НОРМАЛАРНЫ АРТТЫРЫП ҮТИЛӘР

Баулы районы колхозлары Беренче Май алды ярышына кушылдылар. Үзәра ярышучы „Победа“, „Свободный труд“ һәм „Новая деревня“ колхозлары иртә чәчелә торган культураларны чәчүне 25 нче апрельгә төгәлләргә йөкләмә алдылар.

Колхозчылар бу йөкләмәне срогында үтәү өчен көрәшәләр.

„Свободный труд“ колхозы члены иптәш Заитов нормаларны чәчүдә һәр көнне 190 процент итеп үтә. Иптәш Мөжгин 180 процент итеп үтиләр. „Новая деревня“ колхозында чәчүчеләрдән Сабанаев һәм Афанасьев иптәшләр норманы һәр көнне 150 процент итеп үтиләр.

СВОДКА ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

ШӨГЕР, 19 апрель. (Телефон буенча). Тракторларны ремонт ясау буенча Татнаркомзем тарафыннан бирелеп барыла торган һәрбер сводка соңгы вакытта Үзәк МТС ы өчен „уңышлар“ белән тула башлады. Күптән түгел әле сводка бу МТС та тракторларга ремонт ясау планы 50 процентка гына үтәлүен күрсәткән иде. Аннан соң кинәт 70—80 процентка җитүне, ә 10 нчы апрельдәге сводкада инде ремонтның 96,2 процентка кадәр күтәрелүен күрәбез. Әгәр бу сводкага ышансаң, Үзәк МТС ында эш ал да гөл! Ә саннар ышандырырлык. Күрәсез, нинди төгәл, 0,2 процентына кадәр бар!

Чынлап да шулай микән соң? Юк, алай түгел. Бу бары тик күз буяу гына.

Менә фактлар. Мастерской тирәсе тракторлар, җимерек автомашиналар, сабаннар, чәчкечләр, тимер-томырлар белән тулган. Тракторларның кайсысының артлары, кайсыларының радиаторлары юк. Кайберләренә моторлар да куелмаган. МТС тагы 38 тракторның 13 е (34 процент чамасы) әле эшләми.

Менә без дизелле ЧТЗ тракторы янында. Аның янында 3—4 кеше нәрсәдер эшли... Ул 10 нчы номерлы бригада икән.

— Булмы, егетләр, дибез.

— Быел була,—ди, корсы гына итеп.

— Нигә алай, быел?

— Шулай менә,—дип әйтә икенчесе.

— Безнең бригадада 4 трактор эшләргә тиеш. Бер эшләре башланмаган. Аларның артык вакыт үтеп китте инде. Әле бары бер трактор гына колхозда.

— Калганнары?

— Берсе кичә үзебез эшләрчәк Куак юлында киткән иде. Шөгер урамында уч алмаган, батып ята. Икенчесе әле җыелып та бетмәгән. Менә монсы әллә кайчан җыелып беткән булыр иде... механикларның берсе нәрсә эшләвен икенчесе белмәве хур итте ди,— ул.

МТС директоры иптәш Газизов тракторларның хәзергә кадәр ремонттан чыкмавына тулысынча Бөгелмә МТМ ы гаепле, дип күрсәтергә тырыша. Без моны инкар итәргә җыенмыйбыз. МТМ Үзәк МТС ының моторларына ремонт ясауны чиктән тыш соңга калдырган һәм бар. Әлбәттә, МТС эшен артта калдыруга билгеле дәрәҗәдә йогынты ясаган. Ләкин бөтен бәлане МТМ өстенә генә аудару дөрес түгел.

Хәзер МТС усадьбасында ята торган тракторлар арасында моторлары МТМ нан моннан 4—5 көн элек кайтканнары да бар. Ләкин шулай да әле бу тракторлар үз участокларына чыгып китә алганнары юк. Бик күп гайкалар, болтлар, төрле втулкалар җитми. Аларны күптәннән хәзерләп куярга кирәк иде. Ләкин көз көне үк кайтарылган кайбер станокларның файдалану турында кайгыртучы юк. 3 СТЗ тракторының радиаторлары ремонтланмыйча тора. Бу тракторларның моторлары МТМ нан кайтканга бер атна вакыт үтте бит! Күпчелек тракторларга шпорлар белән тәгәрмәчләр юк. Ләкин МТС җитәкчеләре бу турыда кайгыртмыйлар.

Участокларга киткән кайбер тракторларның беренче көнне үк ватылулары ремонтның түбән сыйфатлы итеп үткәрелүен күрсәтә. „Үзәк“ колхозындагы газогенераторлы трактор көн буе диярлек тукталып торды. „Индустрия“ колхозындагы бер трактор подшипниклары эреп, 4 көннән бирле эшләми. Тракторлар бер генә сменада эшлиләр. „Индустрия“ колхозы председателе иптәш Садыйков:

— Без бу турыда 3 көннән бирле МТС ка хәбәр итәбез, әмма бер нәтиҗә дә чыкмый,—ди.

Шушылардан соң МТС җитәкчеләренең гаепне тик МТМ га гына аударулары никадәр урынсыз булуы ачык. Тракторчылар арасында масса-тәрбия эшләренең чиктән тыш начар булуы һәм шуның нәтиҗәсе буларак хезмәт дисциплинасының йомшаруы турында фактларны китереп тормыйбыз.

Үзәк МТС ы чәчүгә әнә шулай, бөтенләй дип әйтерлек хәзерлексез чыкты.

„Кызыл Татарстан“ бригадасы:
М. Хәмидуллин,
Х. Шәмсеттинев.

Алдынгы МТС та

Ворошилов районының Нөркәй МТС ы тракторчылары чәчүдә хезмәт җитештерүчәнлегенең югары үрнәкләрен күрсәтәләр. Барлык тракторлар да өзлексез эшлиләр, күп кенә тракторчылар норманы арттырып үтиләр. Тракторчы иптәш Габдрахманова Гайшә көпчәкле тракторда үз сменасында 15 гектар урынына 27 гектар һәм иптәш Коттусев 25 гектар чәчәләр. Тракторчы Мәхмүт иптәш Хаҗиев норма буенча билгеләнгән 4,25 гектар урынына 6,5 гектар, Маһиҗамал иптәш Дәүләтова 5,4 гектар, Мөхәмәтша иптәш Зарипов 6 гектар сөрәләр һәм Тимер иптәш Галиәхметов үз сменасында 14 гектар урынына 25 гектар культивацияли.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

Йөкләмәләребезне тулы үтәрбез

Беренче Май бәйрәме якынлаша. Бәйрәм алды ярышы көннән-көн киң колач ала. Бөек бәйрәмне производствода яңа казанышлар белән каршыларга—халкыбызның бердәм теләге әнә шундый. Республикабызның азык промышленносте предприятиеләре работниклары да шундый теләк белән сугарылганнар. Алар ярты еллык планны вактыннан элек үтәү өчен көрәшәләр.

„Кызыл Шәрык“ сыра заводы, мальтоз һәм уксус заводы кебек байтак кына алдынгы предприятиеләр үз йөкләмәләрен намус белән үтиләр. Алар беренче квартал планын арттырып үтәделәр. Ә икенче кварталда тагын да яхшырак эшли башладылар. Шик юк, апрель аенда 24,6 мең гектолитр сыра, 300 гектолитр уксус, 260 тонна прянник, 18,1 тонна венский әйберләр, 156 тонна макарон, 144 тонна токмач һәм вермишель, 175 тонна мальтоз, 120 тонна крахмал эшләп чыгару планы вактыннан элек үтәләчәк. Планнан тыш бер ярым миллион сумлык продукция эшләп чыгарачакбыз.

Дөресен әйтергә кирәк, беренче кварталда без канәгатьләнерлек эшләмәдек. Өлкә күләмендә әһәмиятле урын тоткан предприятиеләр буенча беренче квартал планы 99,5 процентка һәм район предприятиеләре буенча 89 процентка гына үтәлде. Барлыгы 2 миллион 68 мең сумлык продукция биреп җиткерелмәде. Микоян исемендәге кондитер фабрикасы, Казан шәһәрендәге саго заводы аеруча начар эшләделәр. Алар үзләренең начар эшләүләре белән наркоматның барлык предприятиеләрен артка өстериләр. Шуңа күрә дә, хәзер без төп игтибарны артта калучы предприятиеләрнең эшен яхшыртуга юнәлттек. Икенче кварталда барлык предприятиеләребезнең дә төгәл эшләүләрен тәэмин итү нигезендә, гомуми күтәрелешкә, республикабызның XX еллыгына ярты еллык планны тулы үтәүгә ирешү өчен барлык чараларны күрәбез. Ярышта алган йөкләмәләребезне тулы үтәү өчен бөтен мөмкинлекләребез бар.

П. Сечин.

ТАССР Азык Промышленносте Халык Комиссары урынбасары.

Ленин районын төзекләндерү

Ленин районы Казан шәһәренең эре промышленность үзәкләренең берсе. Сталинчыл бишьеллыклар чорында бу район аеруча кызу үсте һәм үсә. Дистәләрчә яңа завод, фабрикалар, культура учаклары барлыкка килерелде һәм китерелә.

Районның киләчәге тагын да матуррак. 1940 нчы елда районны төзекләндерү эшенә зур сумалар тотылачак. Мәсәлән, юллар төзелешенә 1,5 миллион сумнан артык акча билгеләнде. Районның үзәк урамнары тоташтан асфальт белән капланачак. Урамнарны яшелләндерү эшенә бер миллион сумга якын, канализация һәм электрофикация эшләренә 120 мең сум акча билгеләнде.

Районны төзекләндерү эшенә билгеләнгән бу зур сумаларны тулы үзләштерү, мактаулы һәм җаваплы бурычларны уңышлы башкару өчен көрәш тирәсенә җәмагатьчелек фикрен туплау—район җитәкчеләренең намус эше.

В. Прокофьев.

Юл төзү эшләре башланды

Әлмәт районының байтак кына колхозлары юл төзелеше сезонын үрнәк хәзерлек белән каршыладылар. Төзү материалларын эш объектларына ташу планы нигездә үтәлде диярлек.

„Ярыш“, „Марат“, „Дирижабль“ һәм Сталин исемендәге колхозларда юл төзелеше буенча оештырылган махсус бригадалар юлларны төзекләндерү эшенә керештеләр. „Ирек“ колхозы (юл эше бригадиры иптәш Шәйхеттинов) үзенә беркетелгән ике километр юлга чуер таш җәю эшен төгәлләде. „Дирижабль“ колхозы членнары үзләренә беркетелгән участокта капиталь ремонт үткәрү эшләрен 1 нче Майга үтәү өчен көрәшәләр.

З. Салахеттинов.

ЛОТЕРЕЯ БИЛЕТЫН ТАРАТУ ТӨГӘЛЛӘНДЕ

Кукмара районы, Мәчкәрә урта мәктәбендә Осоавиахимның башлангыч оешмасы (председателе иптәш Бакиров) Осоавиахимның XIV нче Бөтенсоюз лотереясе билетларын таратуны төгәлләде. Мәктәптә бер көн эчендә 500 сумлык билет таратылды.

Осоавиахим оешмасы районлагы беренче һәм икенче номерлы урта мәктәп коллективларын лотерея билетын тарату буенча социалистик ярышка чакырды.

Г. Сибгатуллин.

ЗУР СТАЖЛЫ ЭШЧЕЛӘР

Вахитов исемендәге жиркомбинатта зур стажлы эшчеләр саны күп кенә. Шәм заводы эшчеләреннән Пургина шушы комбинатта 33 ел, Тимофеева 25 ел, Кондратьева 28 ел, Глухова 28 ел, Титовнина 28 ел, Борисова 35 ел, Малыгина 35 ел, Майорова 27 ел, Димитриева 31 ел эшлиләр.

Зур стажлы эшчеләр комбинатның башка заводларында да һәм цехларында бар. Алар хезмәт җитештерүчәнлегенең яхшы үрнәкләрен күрсәтәләр, норманы бер ярым—ике тапкыр арттырып үтиләр. Зур стажлы эшчеләрнең күбесе соңгы елларда җитәкче постларга күтәрелделәр.

КУЛЬТУРА САРАЕНДА

18 нче апрельдә Ленин исемендәге заводның культура сараенда Татарстанның атказанган артистлары—Мәрьям Рахманкулова, Фәйзулла Туишев һәм артистка Шәрипова иптәшләрнең чыгышлары оештырылды.

Концертта татар халык көйләре һәм татар совет язучыларының, шагыйрьләренең әсәрләре башкарылды. Татар Дәүләт Филармониясе тарафыннан оештырылган бу кичә зур уңыш белән үтте.

ОБОРОНА ЯРЫШЛАРЫ

Кукмара районында мәктәп балаларының оборона ярышлары үткәрелде. Ярышларда 178 укучы катнашты. 1 нче номерлы урта мәктәпнең ГСО командаларына комиссия тарафыннан иң яхшы бәя бирелде. 8 кешедән торган бу команда шәһәр күләмендәге ярышта катнашачак.

Шул ук мәктәп укучыларыннан Садрый Шәйдуллин, Әхәт Хәбибуллин, Миша Данилов, Рим Усманов иптәшләр барлык топографик кагыйдәләрне кулланып, урынны картага төшерүдә һәм флаглар белән сигналлар бирүдә беренчелекне алдылар. 2 нче номерлы урта мәктәпнең ату командасына катнашучылардан Г. Басыйров, мөмкин булган 50 очкодан 47 очко, Гомәр Кәлимуллин 43 очко алдылар. Шәһәр күләмендәге ярышларда катнашу өчен районда 34 кешедән торган команда төзелде.

М. Фазлиев.

КОЛХОЗЧЫЛАР ЯҢА АЛФАВИТНЫ ӨЙРӘНӘЛӘР

Апас районының Ленин исемендәге колхозында (Борнаш авылы) яңа алфавитны өйрәнү эше буенча культармеецлардан Гайнуллин, Вәлиев, Минһаҗова һәм Бикчантаева иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр. Алар 68 кешене яңа алфавит белән укырга һәм язарга өйрәттеләр. Яңа алфавитны өйрәнү курсларын тәмам итүче колхозчылардан 30 кеше „Уку ударнигы“ газетасына язылды.

Х. Х.

Татар җырлары һәм биюләре ансамбле Ерак Көнчыгышка бара

Татарстанның атказанган артисткасы Зөләйха Әхметова җитәкчелегендәге җыр һәм бию ансамбле быелгы җәйге гастрольләр вактында Ерак Көнчыгышка бара. Ансамбль Ерак Көнчыгышта 4 ай булачак һәм күп кенә шәһәрләрдә, шулай ук хәрби частьләрдә концертлар бирәчәк.

Татарстан Дәүләт Филармониясенең директор урынбасары иптәш Раевский гастрольне оештыруга хәзерлек эшләре буенча 10 нчы апрельдә Хабаровскига китте.

Редактор урынбасары
И. УЗБЕКОВ.
Зам. редактора **И. УЗБЕКОВ.**

7 нче май, кич 6 сәгатьтә Казан Дәүләт Ветеринария институтының патологик анатомия кафедрасы аудиториясендә институт гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм түбәндәге темаларда халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ
яклау үткәрелә

1. Ветеринария фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен Казан Дәүләт Ветеринария институты доценты **Н. А. Васнецов.** Тема: „Йорт тавыкларында вегетатив нервлар системасы периферик бүлегенең морфологиясе“.

Рәсми оппонентлар: фәннәр докторы профессор **В. Н. Терновский** һәм фәннәр докторы профессор **А. П. Студенцов.**

2. Ветеринария фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен Краснодар терлекчелек тәҗрибә станциясенең өлкән фәнни сотрудннгы **А. А. Фомин.** Тема: „Английский нәселле ак эре дуңгызның постэмбриональ чорда үсеше турындагы мәсьәләгә карата“.

Рәсми оппонентлар: фәннәр кандидаты доцент **Г. В. Крылов** һәм фәннәр кандидаты доцент **Ф. Ф. Федотов.**

Диссертация материаллары белән институт көтепханәсендә танышырга мөмкин.

600—1

БҮГЕН ТЕАТР ҺӘМ КИНОЛАРДА:

Татар Дәүләт Академия театрында—композитор Салих Сәйдәшевнең иҗад кичәсе. Кичәдә Казан шәһәренең иң яхшы артист көчләре һәм зур симфоник оркестр катнаша.

Татар Дәүләт Опера театры—иртәгә Файдасызга саклану.

Зур театр—Куркынычлы суд.

Цирк бүген эшләми.

„Электро“—Аринка. „Унион“—Моряклар. „Кызыл Йолдыз“—Ташландык. „Чаткы“—Ташландык. „Пионер“—Инженер Кочинның ялгышуы. „Колхозник“—Яңа заманнар. „Рот-Фронт“—Шәхси эш. Культура сарае—Истребительләр.

Чит илләрдә

СКАНДИНАВИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

БЕРЛИН, 18 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә:

10 нчы апрельдә иртә белән Англиянең крейсерлары һәм эсминецлары беренче тапкыр Нарвикка якынлаштылар. Каты сугыштан соң англичаннарның һөҗүме кире кагылды. Англичаннарның 3 эсминецы батырылды, бер эсминец нык зарарланды. Германиянең ике эсминецы нык зарарланып сафтан чыкты. Соңыннан англичаннар тарафыннан диңгездә һәм һавада ясалган атакалар кире кагылды. 13 нче апрельдә англичаннар ярдәм алып зур һөҗүмгә күчтеләр. Германия эсминецлары Англиянең хәрби диңгез көчләренә бухтага керү юлын бикләделәр. Англичаннар Германиянең бер генә карабын да батыра алмадылар.

17 нче апрельдә Англиянең кораллы көчләренең кечерәк кенә берләшмәләре Нарвик районында беренче тапкыр десант төшерергә маташтылар. Дошманның матавшулары кире кагылды.

17 нче апрельдә дошманның Тронгеймга һавадан һөҗүме уңышсыз чыкты.

17 нче апрельдә иртә белән Англия крейсерлары ерактан Ставангерны тупка тоттылар. Германиянең 4 самолеты җимерелде. Шуңа җавап итеп Германиянең хәрби һава көчләре Ставангер районында Англия карабларына атака ясадылар. Англичаннарның бер крейсеры батырылды. Монардан тыш дошманның беренче һәм икенче класс крейсерларына, шулай ук бер эсминецка зиан китерелде.

Осло һәм Конгсвингер районында Германия гаскәрләре алга таба баруларын уңышлы рәвештә дәвам иттерәләр.

Германия самолетлары Арендальдан төньяк-көнчыгыштарак Норвегиянең ике миноносецына атака ясадылар. Бер миноносец нык зарарланды һәм командасы аны ташлап китте.

ЛОНДОН, 18 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгы үткән атнада Англиянең „Ринаун“ линкоры тарафыннан зиан китерелгән „Шарнхорст“ исемле Германия броненосецының Тронгейм якынында икәнлеген хәбәр итә. Тронгейм бухтасында Германиянең сайга утырган крейсеры, шулай ук 3 эсминецы бар.

Агентлыкның хәбәр итүенә караганда, җиргә төшерелгән Англия частьләре Нарвик районында ныгыганнар, ләкин Германия гаскәрләре шәһәрнең бер өлешен әле һаман кулларында тоталар. Англия гаскәрләре Нарвиктан төньяк-көнчыгыштарак төшкәннәр һәм бу районда хәрәкәт итүче Германия частьләрен чолгап алырга тырышалар. Хәбәр итүләренә караганда, Германия морякларының ике группасы Швеция чиген кичкәннәр һәм интернировать ителгәннәр.

ЛОНДОН, 18 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Нарвикта төшкән Англия гаскәрләре чигенеп баручы Германия частьләрен эзәрлеклиләр. Төньяк Норвегиядә Англия частьләре Норвегия частьләре белән элемтә урнаштырдылар. Хәбәр итүләренә караганда, Эльверум районында (Ослодан 100 километр төньяк-көнчыгыштарак) Германия гаскәрләре белән Норвегия гаскәрләре арасында зур бәрелеш башланган. Хенефос районында Германия танклары күренүне хәбәр итәләр. Тронгейм белән Стурлиен (Швеция чигендә) арасындагы бөтен тимер юл немецләр кулында. Һавадан бомбага тоту нәтиҗәсендә кичә немецләр Хегрда норвегиялеләрнең фортларын атудан туктатканнар. Норвегиянең иң көньяк-көнчыгыш өлешендә Норвегия гаскәрләре үзләренең позицияләрен ташлап киткәннәрдер дип уйлыйлар.

НЬЮ-ЙОРК, 18 апрель. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Нарвиктан көнчыгышта, Швеция чиге якынында каты сугышлар бара. Риксгренсен, Бьернефьель районында һәм Нарвик—Кирун тимер юлы буенда көчле сугышлар бара. Стурлиенгә таба юнәлештә Германиянең эре частьләре һөҗүм итәләр. Швеция чиген үтеп чыккан 60 норвегияле солдат Норвегия гаскәрләренең зур югалтулар ясап бөтен көньяк-көнчыгыш фронтта чигенүләрен белдергәннәр.

Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәренә караганда, Нарвик янында Англия гаскәрләре Германия частьләренә атака ясаганнар.

НЬЮ-ЙОРК, 18 апрель. (ТАСС). Америка матбугатының хәбәр итүенә караганда, Германия гаскәрләре Намсостан төньякта һөҗүм итәләр. Англия гаскәрләре Намсоска төшкәннәр.

Норвегия гаскәрләре Ослодан төньяк-көнбатышта Хаделанд районын ташлап киткәннәр.

БЕРЛИН, 18 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросы Англиянең 16 нчы апрельдә Лондон радиостанциясе тарафыннан тапшырылган рәсми хәбәрен юкка чыгара. Бу хәбәр буенча Англиянең сугыш караблары Ромбакс-фиордта портка блокада ясаганнар һәм Нарвикта артиллерия ярдәме белән Англия гаскәрләре төшкән, имеш. Аннары англичаннарның белдерүендә Германия гаскәрләре тауларга чигенделәр һәм шулай итеп Англия һәм Норвегия гаскәрләре арасында кысрыкландылар дип күрсәтелә. Шушы уңай белән Германиянең җитәкче даирәләрендә Англиянең хәрби диңгез көчләре Нарвикка уңышсыз рәвештә аттылар дип белдерәләр. 16 нчы апрельдә Нарвик янында англичаннар десант төшерергә маташмадылар. Нарвик бүгендәге кебек үк 16 нчы апрельдә дә немецләр кулында булды. Нарвиктан Швеция чигенә бара торган тимер юлны алган вакытта гүяки немецләрне чолгап алган Норвегия гаскәрләре таратылдылар. Норвегия гаскәрләренең бер өлеше юк ителде, бер өлеше пленга алынды, калганнары Швеция чиген үтеп чыктылар.

БЕРЛИН, 18 апрель. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр итүләренә караганда, кичә союзникларның диңгез көчләре белән Германиянең диңгез һәм һава флоты арасында Норвегиянең көньяк-көнбатыш ярлары районында зур сугышлар булган. Англичаннарның бер крейсеры юк ителгән, ике крейсерга һәм бер линкорга нык зиан китерелгән.

АКШ белән Исландия арасында дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштырылу

НЬЮ-ЙОРК, 17 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, АКШ ның дәүләт секретаре Хэлл Исландиянең баш министре Йонассоннан телеграмма алганлыгын белдергән. Бу телеграммада Исландиянең АКШ белән турыдан-туры дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштырырга теләве күрсәтелә. Үзенең җавабында Хэлл АКШ хөкүмәтенең хәзерге хәлен искә алып Исландия белән дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштырырга ризалыгын һәм Рейкьявикта (Исландиянең баш шәһәре) Америка илчелеге ачарга уйлаганлыгын белдергән. Заемнар буенча хөкүмәт администраторы Джонс АКШ хөкүмәте тарафыннан Исландия өчен билгеләнгән бер миллион доллар күләмендәге кредитны Исландиянең ала алуын белдергән.

ШВЕЦИЯДӘГЕ ХӘЛ

СТОКҺОЛЬМ, 17 апрель. (ТАСС). Швециянең дәүләт информация идарәсенең хәбәр итүенә караганда, 15 нче апрельдә Норвегиянең 7 самолеты Даларн округында җиргә төшкән. Самолетларны Швеция властьлары саклыйлар. Самолетларның экипажы интернировать ителгән.

Швеция хөкүмәте түбәндәге бухталарда судноларның йөртүне тыю турында бойрык игълан итте: Стермстад, Люсекиль, Уддевалла, Варберг, Хальмстад, Хельсинборг, Ландскруна, Мальме, Треллеборг, Истад, Симрисхамн, Ахус, Сольверсборг, Карлсхамн, Кальмар, Оскархамн, Висибю, Вестенвик, Норрчепинг, Оксельзунд.

Газеталарның хәбәр итүенә караганда, бензиннан башка барлык ягулык запасларына конфискация ясалган. Ягулыкны сату бары тик хөкүмәт комиссиясенең махсус күрсәтмәсе буенча гына рөхсәт ителә. Бөтен илдә һавадан куркыныч хәле турында бойрык чыгарылган. Бойрыкта тревога сигналларын бирү, һава һөҗүменнән саклану буенча команда пунктлары оештыру һәм качу урыннары төзү тәртибе күрсәтелә. Бөтен көнбатыш һәм көньяк Швециядә карангыландыру дәвам итә.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1390. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1513.